РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Ленина, д.14, г.Азнакаево, 423330

Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14. 08. 2023 ел № 31

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
16:44:010105:264 кадастр номеры булган
җир кишәрлеге һәм Азнакай шәһәре
Радужная урамы 3 нче йорт адресы
буенча урнашкан торак биналарны
алу турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 279 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 56.3, 56.6 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 гыйнварыннан 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Радужная урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында»гы карары (22.02.2023 №06, 27.04.2023 №15, 27.06.2023 №20 карарлар редакциясендә) нигезендә карар бирә:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен кадастр номеры 16:44:010105:264 булган, 7920 кв.м мәйданлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Радужная урамы, 3 йорт күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип танылган җир кишәрлеген алырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген муниципаль ихтыяҗлар өчен алуга бәйле рәвештә, милекчеләрдән законда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге торак биналарны алырга:

2.1 Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Радужная ур., 3 йорт, 19 адресы буенча урнашкан торак йортны, кадастр номеры 16:44:010105:2559 гомуми мәйданы 61,8 кв.м.;

2.2. Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Радужная ур., 3 йорт, 13 адресы буенча урнашкан торак йортны, кадастр номеры 16:44:010105:2564 гомуми мәйданы 78,4 кв.м.;

3. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә әлеге карарда күрсәтелгән җир кишәрлекләре һәм торак урыннар хокукына ия булучыларга түбәндәгеләрне җибәрергә:

- әлеге карарның күчермәсен;

- Россия Федерациясе Җир кодексының 56.6 статьясындагы 10 пунктында каралган тәртиптә тапшыру турында хат белән торак урынын алу турында хәбәрнамә;

- Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 4 пунктында каралган муниципаль ихтыяҗлар өчен торак урынын алу турында килешү проекты;

- Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә каплау күләмен бәяләү турында хисап.

4. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә аның күчермәсен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

5. Азнакай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.А. Габдрахманов